Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Сөләй авыл Советы

# КАРАРЫ

03 март 2020 ел

№ 88

Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл Советының 2016 елның 27 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында» 1996 елның 1 апрелендәге 27-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, 2020 елның 22 гыйнварендагы 21-пр номерлы Әлмәт шәһәре прокуратурасы протестын караганнан соң

Сөләй авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл Советының 2016 елның 27 декабрендәге 29 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл Советының 2017 елның 20 сентябрендәге 35 номерлы, 2018 елның 17 июлендәге 49 номерлы, 2019 елның 6 маендагы 67 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче бүлекнең 2.5 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020 елның 1 октябренә кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфасын биләү өчен, һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре урта һөнәри белем бирүне һәм белгечлек буенча эш стажын, әзерлек юнәлешен - кимендә ике ел яисә кимендә өч ел эшләүне күздә тота ала. 2020 елның 1 октябреннән соң әлеге пунктның икенче абзацында каралган вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре 2020 елның 1 октябренә кадәр вазыйфага билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләргә һәм әлеге пункт нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актларда каралган тиешле квалификация таләпләренә карата кулланылмый».

1.2. 7 нче бүлекнең 7.1. пунктында:

а) 2 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында

төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш ) яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында җирлек Советы мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау;

г) җирлек мәнфәгатьләрен идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә, гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) җирлек булган оешмаларда яклау, җирлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкалэтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»

б) түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.1.) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки аша ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;»

1.3. 9 нчы бүлекнең 9.3. пунктының 6 нчы пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ рәвешендә;».

1.4. 22 нче бүлекнең 22.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22.4. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.; »

1.5. 22 нче бүлекнең 22.6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22.6.5. Муниципаль хезмәткәрләргә коррупциячел хокук бозу турында мәгълүмат кергән көннән алып 8, 22, 24 пунктларында каралган түләтүләр муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча хезмәткә яраксыз булу чорларын, аның отпускта булуын исәпкә алмаганда һәм коррупциячел хокук бозу башкарылган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эше каралган вакыт кертелми.».

2. Әлеге карарны Сөләй авылы, Совет урамы, 53а йорты; Урсалбаш авылы, Әхмәдуллин урамы, 114а йорты; Яңа Михайловка авылы, Заречная урамы, 29а территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты "Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сөләй авыл
җирлеге башлыгы — А.З.Бикбаев